## Илдар юморы

Татарда юмор бармы? Нәкъ безнеңчә, нәкъ татарныкы дип әйтерлек юмор? Әгәр юк икән, татар юморы нинди булырга тиеш?

Радиодан йә телевизордан, яки эстрада сәхнәсеннән бәһасе өч тиен дә тормаган «шәрә мәзәкләр», «шаян әсәрләр» тыңларга туры килгән чакларда, җанымны вакыт-вакыт шундый бихисап сораулар бимазалап ала. Шул мәлләрдә күңелемдә, Гафур Коләхмәтовчарак әйткәндә, ике фикер көрәшә башлый:

— Татарда юморның булганы да юк һәм ул мәңге булмас та! — ди Кара фикер.

— Татарда юмор бар һәм ул — мәңгелек! — ди Якты фикер (нигәдер аны, Гафур Коләхмәтовча, Кызыл фикер дип әйтәсем килми).

— Бүгенге юморны чүп чиләгенә себереп түгәргә кирәк! — ди Кара фикер. — Татар юморы шундый буламыни?!

— Синең белән килешәм! — ди Якты фикер. — Чынлап та, татар юморын чүп басты. Әмма мин, юмор бар ул, дип әйтәм. Мин монда татар әдәбиятындагы көлкеле һәм шаян, шул ук вакытта төртмәле-чәнечкеле, каһкаһәле шаһ әсәрләрне күз уңында тотам…

— Сүзеңне раслап, берничә мисал китер! — ди Кара фикер.

— Рәхим ит! — ди Якты фикер һәм әдәбиятыбыз җәүһәрләре саналган шаян әсәрләрне искә төшерә башлый…

Бу урында, Якты фикернең сүзен куәтләп, мәшһүрләребез Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гамил Афзал, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев, Фаил Шәфигуллин, Туфан Миңнуллин, Альберт Яхин исемнәрен атап үтү дә җиткән булыр иде кебек. Юк, безнең базда әле дары бетмәгән! Тагын Фәнзаман Баттал, Камил Кәримов, Марсель Галиев, Зөлфәт Хәким, Әмирҗан Моталлаповларыбыз бар. Чагыштырмача яшь Ленар Шәех белән юморда шактый тирәнгә тамыр җибәргән Илдар Хәйруллинны да онытып җибәрмик тагын!

Сүз башым бит шүрәле иде дигәндәй... Мин нәкъ менә Илдар Хәйруллин турында, каләмдәшем һәм замандашымның җыйнак һәм тыйнак иҗаты хакында әйтмәкче идем бит.

Татар матбугатын мәктәп елларыннан (узган гасырның 70 нче еллары башыннан) бирле даими укып барган кеше буларак, Илдар Хәйруллин иҗаты белән күптәннән танышмын, дип әйтсәм, бер дә хилафлык булмастыр. 1973 елда унбиш яшьлек Илдарга «Яшь ленинчы» газетасында җиңү китергән хикәяне дә хәтерлим әле мин. Ул елда әлеге басманың бер санында мин бахырыгызның «Хыял» дигән тәүге шигыре басылган иде. Димәк, без — бер-берсе белән таныш булмаган ике үсмер — шул елларда ук, иңгә-иң торып дигәндәй, әдәбият иленә тәүге адымнарыбызны атлаганбыз икән.

Илдар Хәйруллинны, юморист буларак, укучыларга «Татарстан яшьләре» газетасы ачты дип беләм. Илдар бер чорда бу басманың бик актив авторы булды. Дөрес, аның аерым әсәрләре үзен дөньяга иңдергән Кукмара белән әлеге көнгәчә яшәргә, иҗат итәргә көч биреп торган «пропискалы төбәге» Түбән Кама районнары газеталарында, шулай ук «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Чаян», «Сөембикә», «Мәйдан», «Казан утлары» кебек мәртәбәле басмаларда да дөнья күрде.

2006 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булган каләмдәшем Илдар Хәйруллинның мине аеруча сокландырган бер ягы, бер сыйфаты, ягъни язу өслүбе – ул да булса аның сәхнә өчен монологлар иҗат итүе. Бүгенге көннең кайбер шаян яки каһкаһәле әсәрләрен сәхнәдән укып булмый. Тамашачы җөмлә саен, һич югы, ике җөмләгә бер мәртәбә көлмәсә, ул – сәхнә әсәре түгел, өстәвенә җөмләләр дә кыска булырга тиеш. Мин шулай уйлыйм. Илдар дустыбыз Хәйруллин исә, рәхмәт төшкере, моның үзенчәлекле нечкәлеген, «хәйләсен» белә, әйтер идем, нечкә тоемлап, тирәнтен аңлап, тамашачыны, тыңлаучыны күз алдына китереп һәм әсәрнең кай өлешендә аларның нинди реакция белдерәсен белеп яза. Афәрин, юмордаш!

Юмордаш, юмор дигәннән… Илдар Хәйруллин юморындагы геройлар – безнең арабыздагы гади-гадәти кешеләр. Кечкенә кешеләр димим, бу артык тарайту, геройларны тар даирәдә генә калдыру булыр иде. Язучы әсәрләренең үзәгендә үз татарыбызның төрле катлам кешеләре тасвирлана, аларның холык-сыйфатлары, ситуациягә карап, төрле яссылыкта ачыла. Хикәяләрнең байтагында автор чишелешне уңай (үзенчә) хәл итүне укучыларның (тыңлаучыларның) үз хөкеменә калдыра. Бу да – үзенә күрә кызык бер алым, ысул, минемчә.

Илдар Хәйруллин хикәяләрендәге һәм монологларындагы геройларның исемнәре дә аерым игътибарга лаек: Фәризун, Тәслимә, Мәүлихан, Фәндәрия, Нурәхмәт, Гөлфизә, Ләйфрүзә, Сабирҗан, Рабига, Вәлихан, Минзәрия… Автор геройларына шундый тормышчан исемнәр кушып ота, әсәрнең ышандыру көчен тагы да арттыра төшә дип саныйм. Һәрхәлдә, артык күп яңгыраган герой исемнәре Гали Вәлиеч тә Барый Әптәреч, Экзема Сәфәргалиевна да Мәчтүрә Иблисовна түгел инде…

Илдар Хәйруллин юморы – чын мәгънәсендә халыкчан юмор. Әсәрләрендә автор төрле мөгез чыгарулар, шак-

катризмнар белән мавыкмый, көлдерәм дип кылтаймый, мин-минләнми, киресенчә, гади, сыгылмалы сөйләм теле белән укучыны һәр вакыйга эченә бөтереп алып керә һәм шул вакыйганың финалына кадәр, ягъни әсәрнең соңгы ноктасынача «җитәкләп диярлек» озата.

Татар юморын әллә каян түгел, халык мәзәкләреннән эзләргә кирәк, дип еш әйтәм... Ә нәрсә соң ул халык мәзәге? Ул — кичә яисә бүген уйламаганда-көтмәгәндә синең һәм минем (яки бүтәннәр) белән булган көлкеле хәл-вакыйга. Мөхтәрәм Илдар Хәйруллин кебек үткен күзле, сак колаклы әһле каләмнәр исә андый очракларны — күргән-ишеткәннәрне — шундук кәгазьгә төшерүчән була, берзаман ул хәл-вакыйгалар, байтак туплангач, яратып укылышлы китап булып чыгуы да ихтимал. Илдар Хәйруллинның әлеге китабы шикелле.

Мин әйттем, укучым. Сиңа ошбу китапны ләззәтләнеп укырга, ә авторга исә илһамланып янә язарга да язарга язсын. Амин!

***Ләбиб Лерон,***
*М. Җәлил исемендәге*
*Республика премиясе лауреаты*

## ЯРДӘМЧЕ

Кичке ашка Фәризун галстугын салмыйча гына килеп утырды. Озак еллар тупланган ачы тәҗрибә буенча, хатыны Фәндәрия бу хәлнең ахыры юньле бетмәячәген бик яхшы аңлый иде.

— Карчык, ни бит әле, — дип, ир алдындагы аш тәлинкәсен читкәрәк этеп куйды һәм: — Өйдә болай да эш күп иде, тагын үрдәк-чебеш алгансың, көне буе бакчада казынасың, яшең бара, җитешмисең, миңа бөтенләй игътибарың юк, болай яшәп булмый, берәр ярдәмче кирәк сиңа, — диде.

— Көне буе эшләп арыгач, мужик кайгысымы монда... Тукта, нәрсә сөйлисең, нинди ярдәмче ул тагын? — дип, Фәндәрия ялт итеп ире ягына карады.

— Минем дуслар күптән үзләренә яшь ярдәмче алып бетерделәр. Хатыннары компьютерга өйрәнмәгән, машина йөртә белмиләр, заманалар үзгәрде, яшьләрсез яшәп булмый хәзер.

Ирләрнең лыгырдавыннан Фәндәрия күпхатынлылык турында ишетеп белә иде. Бу турыда тыңлаганда, ул һаман «ярар, сөйләнүдән узмаслар әле, хыяллансыннар» дип, борын астыннан көлеп йөрде. Хәзер исә ничәмә ел бергә яшәгән, «почти тугрылыклы» иренең яшь хатын турында ачыктан-ачык әйтүе аны бик нык гаҗәпкә калдырды.

— Кит, нәрсә сөйлисең, картаеп беткәч, яшьрәге кирәк булдымыни? — дип, каушап калган хатын кулындагы